ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

21 сентябрь 2020 ел № 718

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 апрелендәге 346 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 апрелендәге 346 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кыскача коэффициентлар

| Вазыйфа атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| 1. Бюджет өлкәсе оешмалары | |
| Оешма җитәкчесе | 2,25 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 |
| Оешма составындагы идарә башлыгы | 1,8 |
| Идарә башлыгы урынбасары | 1,7 |
| Бүлек башлыгы, җитәкче ярдәмчесе | 1,65 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,55 |
| Баш белгеч | 1,4 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,17 |
| I категорияле белгеч | 1,12 |
| II категорияле белгеч | 1,1 |
| Белгеч | 1,08 |

Искәрмә:

Бер үк вакытта структур бүлекчә җитәкчесе булган җитәкче урынбасарының вазыйфаи окладлары күләме җитәкче урынбасары вазыйфасы буенча билгеләнә.

Кабул итү бүлмәсе мөдирләренең (башлыкларының), беренче бүлек, гомуми бүлек, канцелярия, хуҗалык бүлеге һәм башка шундый бүлекчәләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары тиешле оешманың баш, әйдәп баручы һәм башка белгечләренең вазыйфаи окладлары дәрәҗәсендә билгеләнә;

2) әлеге карарның 3 нче кушымтасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар».

2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 апрелендәге 346 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән билгеләнгән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренең,

белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи оклады күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН" ОГРН 1061685000024 "ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516